ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ
**КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында, шул исәптән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан куелган мәсьәләләр буенча, хисап бирү хакында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Регламентының $190^2$ статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән мәсьәләләр исемлеген Татарстан Республикасы Президентына җибәрергә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Ю.З. Камалтынов

Казан шәһәре,
2020 елның 13 феврале
№ 264-VI ДС

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Президиумының
2020 елның 13 февралендәге
264-VI ДС номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары эшчәнлеге турында Татарстан Республикасы Дәүләт Советы комитетларыннан һәм депутат берләшмәләреннән Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә торган мәсьәләләр исемлеге**

*Граждан җәмгыяте*

1. Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итүгә әзерлек кысаларында Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан башкарыла торган эш турында.

2. Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан гражданнар мөрәҗәгатьләрен караунын (үтәүнең) нәтиҗәлелеге турында.

3. Граждан инициативаларын, шул исәптән проекты «Экотектоника» Бөтенроссия экологик архитектура һәм төзелеш конкурсында икенче урын алган «Савиново» табигый ландшафт паркын төзү буенча җәмәгать инициативасын, гамәлгә кертү буенча чаралар турында.

4. Татарстан Республикасында административ каршылыкларны киметү буенча чаралар системасын гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге турында.

*Икътисад, бюджет*

5. Соңгы 10 ел эчендә Татарстан Республикасы икътисадының чимал керемнәренә бәйлелеге кимү динамикасы нинди?

6. Россия Федерациясендә һәм дөньяда Татарстан Республикасының конкурентлыкка сәләте рейтингы нинди?

7. «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасы кысаларында хезмәт җитештерүчәнлегенең үсү динамикасы нинди? Булдырылган югары квалификацияле эш урыннары санын күрсәтергә.

8. Капитал салуларны яклау һәм кызыксындыру турында законнар пакеты кабул ителү нәтиҗәсендә Татарстан Республикасында гамәлгә ашыру өчен ниятләнгән инвестицияләр күләмен күрсәтергә һәм инвестицион проектларны санап үтәргә.

9. Татарстан Республикасы бюджетының керемнәр базасын арттыру буенча күрелә торган чаралар хакында.

10. «Татфондбанк» гавами акционер җәмгыятенә кертем салучыларның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү буенча күрелгән чаралар хакында.

11. Цифрлы технологияләр кертүдән Татарстан Республикасында җыелма икътисадый тәэсир нинди?

12. Табигать ресурсларыннан файдаланган өчен түләүләр белән идарә итү буенча бюджет вәкаләтләренең 2019 елда Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан үтәлеше турында.

13. Татарстанның туристлык җәлеп итүчәнлеген арттыру буенча чаралар хакында.

14. Татарстан Республикасы территориясендәге барлык тарихи биналарны торгызу һәм Татарстанның туристлык маршрутына кертү максатыннан аларга инвентаризация үткәрү турында.

15. Хуҗасыз объектларны киләчәктә муниципалитетларның һәм махсуслашкан оешмаларның милкенә тапшыру максатыннан Татарстан Республикасының газ һәм электр хуҗалыгына инвентаризация үткәрүне төгәлләү турында.

16. Европа – Көнбатыш Кытай халыкара транспорт коридоры (ХТК) автомобильләр юлы өлешенең Шәле (М-7) – Баулы (М-5) участогында республика территориясе аша узуын раслау өчен Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан күрелгән чаралар хакында.

*Торак шартларын яхшырту,*
*торак-коммуналь хезмәтләр күрсәтү*

17. Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондын булдыру перспективалары турында. Республиканың муниципаль берәмлекләрендә социаль наем буенча торак алу өчен чиратта торучылар санын күрсәтергә.

18. Тузган һәм авария хәлендәге торак фондында яшәүче гражданнарны күчереп урнаштыру мәсьәләләрен хәл итү перспективалары турында.

19. Торак шартларын яхшыртуга мохтаҗ бюджет өлкәсе хезмәткәрләрен, бигрәк тә кадрлар кытлыгы югары дәрәҗәдә булган тармакларда, арендага яисә эш урыныннан бирелгән торак урыннар белән тәэмин итүгә юнәлтелгән чаралар турында.

20. Ятим балаларны һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны, инвалидларны һәм инвалид балалары булган гаиләләрне торак урыннар белән тәэмин итү максатларында күрелә торган чаралар турында.

21. Өч һәм аннан күбрәк баласы булган гражданнарга бирелә торган җир кишәрлекләрен инженерлык һәм транспорт инфраструктурасы белән тәэмин итү буенча Татарстан Республикасы Хөкүмәте кабул иткән чаралар турында.

*Сәламәтлек саклау*

22. Казан шәһәрендә күппрофильле балалар хастаханәсен һәм «Республика йогышлы авырулар клиник хастаханәсе» дәүләт автоном сәламәтлек саклау учреждениесенең икенче чиратын төзү (балалар корпусы төзелеше) перспективалары турында.

23. Татарстан Республикасы бюджетыннан түбәндәгеләрне дарулар белән тәэмин итүгә өстәмә акчалар бүлеп бирү (нинди күләмдә) чаралары турында:

– сирәк очрый торган (орфан) авырулардан интегүче гражданнарны;

– онкологик авырулар, шикәр чире, бронхиаль астма ачыклану ешаюга бәйле рәвештә саннары арта барган региональ ташламалардан файдаланучыларга.

24. Перспективалар турында:

– офтальмология үзәге төзү (2018 елның октябренә катарактага операция ясауны көтү чиратында – 16911 кеше, 2884 кешегә операция ясалды);

– ишетү проблемалары булган балалар өчен махсуслаштырылган реабилитация үзәге ачу;

– белгеч-сурдологларны һөнәри яңадан әзерләү яисә әзерләү факультеты ачу;

– балаларга биш ел саен алмаштырылырга тиешле сөйләм процессорын алмаштыру буенча операциягә кадәрге югары технологияле ярдәм, шул исәптән түләүсез ярдәм күрсәтү;

– Татарстан Республикасыннан читтә һәм чит илләрдә операция ясауга мохтаҗ балаларга операцияләр ясауны финанслауны арттыру;

– онкология белән авыручыларны тормыш өчен кирәкле булган кыйбатлы препаратлар белән тәэмин итүгә акча бүлүне килештерүләр узу чорына бу препаратлар белән тәэмин итүне, шулай ук тормыш өчен кирәкле препаратлар исемлегенә кертелмәгән табиб билгеләве буенча кыйбатлы дарулар белән тәэмин итүне финанслау.

*Социаль сәясәт, аерым категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чаралары*

25. Эшсез калган гражданнарны эшкә урнаштыру өчен шартлар тудыруга юнәлдерелгән чаралар турында. Вакытлыча эшсез затларга социаль ярдәм чаралары хакында.

26. Бала караган өчен пособиене Татарстан Республикасы дәүләт хезмәтләре күрсәтү порталы аша рәсмиләштерүнең мөмкин булган перспективалары турында.

27. Инвалидлар, бала коляскасы белән йөрүче җәяүлеләр өчен уңайлы мохит тудыру турында. Сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән җәяүлеләрнең тоткарлыксыз хәрәкәт итүен тәэмин итү максатларында юлларга һәм тротуарларга инвентаризация үткәрү турында.

28. Җәмәгать транспортында йөрү өчен айлык акчалата түләү алучы пенсионерлар санын факттагы ихтыяҗны истә тотып арттыру максатларында пенсионерларның мөлкәт белән тәэмин ителеш дәрәҗәсен бәяләү параметрларына төзәтмәләр кертү перспективалары турында.

Мөлкәт белән тәэмин ителеш шартларына бәйле рәвештә пенсионерларга аерым социаль ярдәм чараларын бирү шартлары билгеләнгән «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 7 мартындагы 163 номерлы карары үз көченә кергәннән соң янга калган акчалар нинди максатларга юнәлдерелде?

29. Инвалид балаларның, сәламәтлеге мөмкинлекләре чикләнгән балаларның һәм ВИЧ-инфекцияле балаларның ялын оештыру чаралары турында.

30. Татарстан Республикасында «сугыш чоры балаларына» социаль ярдәм чараларын оештыру перспективалары турында, шул исәптән:

– «сугыш чоры балалары» статусын билгеләү;

– «сугыш чоры балалары» ташламалы категориягә керүчеләрнең санын ачыклау;

– Россия Федерациясенең башка субъектлары тәҗрибәсен исәпкә алып, «сугыш чоры балаларына» ярдәм итүнең мөмкин булган чаралары;

– әлеге категориядәге гражданнарга социаль ярдәм чараларын финанслауның планлаштырыла торган күләме.

*Мәгариф, мәдәният*

31. Мәктәп укучыларын һәм студентларны җәмәгать транспортына ташламалы юл билетлары белән тәэмин итү мәсьәләсен уңай хәл итү перспективалары турында.

32. Мәктәпкәчә балалар учреждениесендә баланы карап торган өчен түләү структурасын ярдәмче персоналның хезмәте өчен түләүне республика яисә муниципаль өлешкә күчерү өлешендә финанслау чыганаклары буенча (Татарстан Республикасы бюджеты – муниципаль бюджет – ата-ана түләве) үзгәртү перспективалары турында, бу, бала җитди сәбәпләр аркасында балалар бакчасына йөрмәгән очракта, ата-ана түләвен алмау мөмкинлеге бирәчәк.

Бала җитди сәбәп аркасында балалар бакчасына йөрмәгән очракта, ата-ана түләвен алмауның башка вариантлары турында.

33. Гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны туклану белән тәэмин итүгә айлык акчалата түләүләр күләмен арттыруга юнәлдерелгән чаралар турында.

34. Физик культураны һәм спортны үстерү һәм финанслау турында. Барлык яшь төркемнәре өчен бюджет (гражданнар өчен бушлай) секцияләре санын арттыру мөмкинлеге турында.

35. Шәһәр мәктәпләрендә спорт залларына капиталь ремонт ясау чараларын финанслау максатларында аерым максатчан дәүләт программасы (яисә ярдәмче программа) эшләү перспективалары турында.

36. Гомуми белем бирү оешмаларында азык-төлек блокларын модернизацияләү (җиһазларны алыштыру яки яңалары белән җиһазландыру) һәм ашханәләрне реконструкцияләү (утыру урыннарын арттыру максатларында) өчен күрелә торган чаралар турында.

37. Татарстан Республикасының югары уку йортларында һәм һөнәри белем бирү оешмаларында түбәндәге аерым категориядәге гражданнар өчен бюджет урыннары бүлеп бирү программасын гамәлгә ашыру мөмкинлекләре һәм сроклары турында:

– 25 яшькә кадәрге ялгыз аналар;
– инвалид балалар тәрбияләүче аналар;
– авыл җирендә яшәүче күп балалы аналар;
– авыл җирендә яшәүче үзмәшгуль булып теркәлгән аналар.

38. Россия Федерациясе Президентының Россия Федерациясе Федераль Собраниесенә Юлламасын 2020 елда музыка һәм сәнгать мәктәпләрен ремонтлау өлешендә гамәлгә ашыру һәм алдагы елларга планнар турында, шулай ук башка мәдәният учреждениеләрен һәм гомуми белем бирү оешмаларын, шул исәптән «Үсеш нокталары» белем бирү үзәкләрен заманча җиһазлар белән тәэмин итү перспективалары турында.

39. Мәдәният өлкәсендә хезмәт хакын арттыру перспективалары турында.

*Җәмәгать иминлеге*

40. Татарстан Республикасында юл-транспорт һәлакәтләре санын һәм юлларда һәлак булуны киметү буенча күрелә торган чаралар турында.

41. Автомобиль юллары торышына җәмәгать контроле системасының («Җәмәгать контроле» ДИС) нәтиҗәлелеге хакында.

42. Татарстан Республикасында халыкны янгын куркынычсызлыгы чараларына өйрәтүне оештыру буенча күрелә торган чаралар турында.

43. Татарстан Республикасында мәгариф учреждениеләрендә балаларның иминлеген тәэмин итү һәм балигъ булмаганнар арасында хокук бозулар санын киметү буенча күрелә торган чаралар хакында.

44. Тәмәкесез никотинлы катнашмаларны таратуга бәйле рәвештә Татарстан Республикасында наркоманияне һәм токсикоманияне профилактикалау буенча күрелә торган чаралар турында.

45. Криминаль җинаятьчел төркемнәргә, яшүсмерләр криминаль төркемнәрен дә кертеп, каршы көрәш хакында.

46. Юлларда теләнү өчен инвалидлардан файдалануга бәйле хокук бозуларга каршы көрәшкә юнәлдерелгән чаралар турында.

47. Социаль җаваплылыгы түбән булган затларның үз-үзләрен тотышы җәмгыятькә каршы булуга һәм М-7 трассасы буенча территорияләрнең чүпләнүенә каршы көрәш өлешендә Татарстан Республикасы имиджын яхшыртуга юнәлдерелгән чаралар хакында.

*Экология, авыл хуҗалыгы мәсьәләләре, бакчачылык*

48. Татарстан Республикасы Хөкүмәте тарафыннан Идел елгасында су дәрәҗәсенең минималь күрсәткечтән түбән төшүенә юл куймау өчен күрелә торган чаралар турында.

49. Гомумтаралган файдалы казылмаларны, шул исәптән авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдә, законсыз чыгару фактларын ачыклауга һәм бетерүгә юнәлдерелгән чаралар хакында.

50. Татарстан Республикасында автомобиль транспортының атмосфера һавасы торышына тискәре йогынтысын киметү буенча күрелә торган чаралар турында.

51. Каты коммуналь калдыклар күләмен киметүгә юнәлдерелгән чаралар хакында. Каты коммуналь калдыкларны аерым җыюны кызыксындыру механизмы булдыру турында.

52. Татарстан Республикасында хуҗасыз йорт хайваннарына карата мөнәсәбәт буенча мәсьәләләрне җайга салу өлешендә күрелә торган чаралар турында.

53. Хосусый милектәге һәм озак вакыт дәвамында билгеләнеше буенча файдаланылмый торган авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрне максатчан файдалануга юнәлдерелгән чаралар хакында.

54. Татарстан Республикасы территориясендә туфракларның уңдырышлылыгын саклауга һәм арттыруга юнәлдерелгән чаралар турында.

55. Җир кишәрлекләренә, шул исәптән коммерциячел булмаган бакчачылык яисә яшелчәчелек территорияләре чикләрендә дә, комплекслы инвентаризация үткәрү һәм үзәкләштерелгән кадастр исәбенә алу сроклары хакында.

56. Коммерциячел булмаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтләрен хуҗалык-көнкүреш суы белән тәэмин итү максатларында кулланыла торган җир асты суларын чыгару өчен җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын бирү процедурасын гадиләштерү перспективалары турында.

57. Гомуми файдаланудагы җирләрне коммерциячел булмаган бакчачылык яисә яшелчәчелек ширкәтләре әгъзаларының уртак милкенә тоткарлыксыз тапшыруга юнәлдерелгән чаралар хакында.

58. Селекция эшен (үсемлекчелек, нәселле терлекчелек һәм кошчылык) торгызу Татарстан Республикасы дәүләт программасын эшләү перспективалары турында һәм алга таба Россия базарына чыгу.

*Җирле үзидарә мәсьәләләре*

59. Җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен, шулай ук җирле үзидарә органнарына тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен финанс белән тәэмин итү хакында.

60. Җирле үзидарә органнары тарафыннан халыкны су белән тәэмин итү һәм су җибәрү өлкәсендәге вәкаләтләрне тәэмин итү чаралары турында.

61. 2019 елда гражданнарның ихтыярый салымы программасын гамәлгә ашыру хакында һәм 2020 елга фаразлар турында.